ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2023 г. Казань № 441-29/тэ-2023

«Нармонка коммуналь сервисы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2024 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 08.12.2023 № 53-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Нармонка коммуналь сервисы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Нармонка коммуналь сервисы» ҖЧҖ) тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) шушы карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 441-29/тэ-2023
карарына кушымта

«Нармонка коммуналь сервисы» ҖЧҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2024 елга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см² кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см² кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см² кадәр | 13,0 кг/см² югары | |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Нармонка коммуналь сервисы» ҖЧҖ <*> | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 761,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1 920,26 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге